**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Әлкәй авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Әлкәй авылы №10 « 12» декабрь 2025 ел

**2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына**
**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге бюджеты турында**

**Статья 1**

1. 2026 елга Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге бюджетының төп характеристикаларын түбәндәгечә расларга:

1) Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге бюджеты керемнәренең фаразлана торган гомуми күләмен 3 699,1 мең сумм итеп;

2) Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының гомуми күләмен 3 699,1 мең сумм итеп;

3) Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге бюджеты кытлыгын 0,0 мең сум итеп.

2. 2027 елга һәм 2028 елга Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге бюджетының төп характеристикаларын түбәндәгечә расларга:

1) 2027 елга Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге бюджеты керемнәренең фаразлана торган гомуми күләмен 3 761,9 мең сум һәм 2028 елга 3 865,0 мең сум итеп;

2) 2027 елга Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының гомуми күләмен 3 761,9 мең сум, шул исәптән шартлыча расланган чыгымнарын 87,9 мең сум итеп һәм 2028 елга 3 865,0 мең сум шул исәптән шартлыча расланган чыгымнарын 177,5 мең сум итеп;

3) 2027 елга Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге бюджеты кытлыгын 0,0 мең сум һәм 2028 елга 0,0 мең сум итеп.

3. 2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларын әлеге Карарның 1 нче кушымтасы нигезендә расларга.

**Статья 2**

1. 2027 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлегенең муниципаль эчке бурычының иң югары чиге 0,0 мең сум күләмендә, шул исәптән Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлегенең муниципаль гарантияләре буенча эчке бурычының иң югары чиге Россия Федерациясе валютасында 0,0 мең сум күләмендә расларга.

2. 2028 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлегенең муниципаль эчке бурычының иң югары чиге 0,0 мең сум күләмендә, шул исәптән Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль

районы Әлкәй авыл җирлегенең муниципаль гарантияләре буенча эчке бурычының иң югары чиге Россия Федерациясе валютасында 0,0 мең сум күләмендә расларга.

3. 2029 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлегенең муниципаль эчке бурычының иң югары чиге 0,0 мең сум күләмендә, шул исәптән Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлегенең муниципаль гарантияләре буенча эчке бурычының иң югары чиге Россия Федерациясе валютасында 0,0 мең сум күләмендә расларга.

**Статья 3**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге бюджетында 2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге бюджеты керемнәренең фаразлана торган күләмнәрен әлеге Карарның 2 нче кушымтасы нигезендә исәпкә алырга.

**Статья 4**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге бюджетында 2026 елга бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә Азнакай муниципаль районы бюджетыннан алына торган дотация 6,6 мең сум, 2027 елга 6,7 мең сум, 2028 елга 6,7 мең сум, күләмендә исәпкә алырга.

**Статья 5**

1. Россия Федерациясе Бюджет кодексының 142.5 статьясы нигезендә, җирлек халыкны мәдәният учреждениеләре хезмәтләре белән тәэмин итү өчен шартлар булдыруга, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкалəтләренең бер өлешен гамәлгә ашыру өчен төзелгән килешүләр нигезендә, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Әлкәй авыл җирлеге бюджетыннан Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы бюджетына күчерелергә башка бюджетара трансфертлар күләмен 2026 елга 435,3 мең сум, 2027 елга 276,4 мең сум, 2028 елга 105,3 мең сум күләмендә расларга.

2. 2026 елда һәм 2027, 2028 еллар план чорында Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы бюджетына әлеге статьяда каралган субсидияләр, башка бюджетара трансфертлар ай саен тигез өлешләр белән башкарыла дип билгеләргә.

**Статья 6**

1. 2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының ведомство структурасын әлеге Карарның 3 нче кушымтасы нигезендә расларга.

2. 2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге бюджет ассигнованиеләрен бюджетлар чыгымнары классификациясе бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары (Татарстан Республикасының Азнакай муниципаль районы программалары һәм эшчәнлекнең программага карамаган юнәлешләре), чыгымнар төрләре төркемнәре буенча бүлүне әлеге Карарның 4 нче кушымтасы нигезендә расларга.

3. 2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына бюджет ассигнованиеләрен бюджетлар чыгымнары классификациясенең максатчан статьялары (Татарстан Республикасының Азнакай муниципаль районы программалары һәм эшчәнлекнең программага карамаган юнәлешләре), чыгымнар төрләре төркемнәре, бүлекләре, бүлекчәләре буенча бүлүне әлеге Карарның 5 нче кушымтасы нигезендә расларга.

4. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге бюджет ассигнованиеләренең гавами норматив йөкләмәләрне үтәүгә юнәлдерелә торган гомуми күләмен 2026 елга 0,0 мең сум, 2027 елга 0,0 мең сум һәм 2028 елга 0,0 мең сум күләмендә расларга.

**Статья 7**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге бюджетында 2026 елга Азнакай муниципаль районы бюджетыннан алына торган хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алу вәкаләтләрен тормышка ашыру өчен субвенцияләр күләмен 221,5 мең сум күләмендә, 2027 елга 247,2 мең сум күләмендә, 2028 елга 315,3 мең сум күләмендә исәпкә алырга кирәк.

**Статья 8**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Әлкәй авыл җирлеге үзидарә органнары, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Әлкәй авыл җирлеге муниципаль казна учреждениеләре яңа функцияләр яисә вәкаләтләр бирүгә бәйле рәвештә карарлар кабул итү очракларыннан тыш, 2026 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Әлкәй авыл җирлеге үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренең һәм муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең санын арттыруга китерә торган карарлар кабул итәргә хокуксыз.

**Статья 9**

Татарстан Республикасы Финанслар министрлыгы казначылык Департаментының Азнакай районы һәм шәһәре буенча территориаль булекчәсе төзелгән килешүләр нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге бюджетын үтәү буенча аерым функцияләрне гамәлгә ашыра.

**Статья 10**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге бюджетының 2026 елның 1 гыйнварына калган акчалары Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге исеменнән төзелгән муниципаль контрактларның шартлары нигезендә товарлар белән тәэмин итү, эшләр башкару, 2027 елда түләнергә тиешле хезмәтләр күрсәтүгә муниципаль контрактлар суммасыннан артмаган күләмдә, 2028 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге Башкарма комитеты тиешле карар кабул иткән очракта әлеге максатларга тиешле бюджет ассигнованиеләрен арттыруга җибәрелә.

**Статья 11**

Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге Советының бюджет, финанслар, салымнар һәм икътисад буенча даими комиссиягә йөкләргә.

**Статья 12**

Әлеге Карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo.tatarstan.ru.

**Статья 13**

Әлеге Карар 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Рәис А.Н.Арсланов